| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**БОЕРЫК**

27.01.2020 Казан шәһәре 17-од

«Минем шәҗәрәм»
Республика генеалогик тикшеренүләр
бәйгесе турында

Буыннар арасындагы бәйләнешләрне саклау һәм үстерү, гаиләдәге мөнәсәбәтләрне ныгыту, киң җәмәгатьчелекнең Татарстан Республикасы һәм үз нәсел шәҗәрәсе тарихына кызыксынуы артсын, тарихи үзаңы формалашсын һәм патриотизм тойгысы тәрбияләнсен өчен, шулай ук архив материалларын өйрәнүгә тартылсыннар, гомуми һәм җирле тарихыбызны тирәннәнрәк өйрәнсеннәр дигән максатта Б О Е Р А М:

1. 2020 елда узачак «Минем шәҗәрәм» Республика генеалогик тикшеренүләр бәйгесе Нигезләмәсен (беркетелгән) раслау.
2. «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Дәүләт бюджет учреждениесенең Генеалогик характердагы гозерләр белән эшләү бүлегенә эшлекле төркем төзергә, җаваплы башкаручыларны билгеләргә, «Минем шәҗәрәм» бәйгесен оештыру һәм генеалогик тикшеренүләр уздыру буенча оешманың юл картасын булдырырга, «Минем шәҗәрәм» Республика генеалогик тикшеренүләр бәйгесен 2020 елның 19 февраленнән алып 20 апреленә кадәр уздырырга (Гәптерәхимов Р.А.).
3. Финанс-икътисад бүлегенә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 10.06.2016 датасы һәм 395 нче номеры белән расланган карары буенча «2016-2022 нче елларда Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» Дәүләт программасы нигезе буенча каралган акчаларны Бәйгенең җиңүчеләренә түләүне тормышка ашыру.
4. Дәүләт Комитетының «Минем шәҗәрәм» генеалогик тикшеренүләр Республика бәйгесе турында» Боерыгының 19.02.2019 датасы һәм 31-од номеры белән тамгалап расланганын гамәлдән чыккан дип исәпләргә.

5. Әлеге Боерык рәсми бастырылган көннән алып үз көченә керә.
6. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Рәис Г.З. Габдрахманова